СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“28” сентябрь 2018 ел** **№60**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 24 сентябрендәге 5 номерлы «референдум үткәрүне оештыру турында» гы Карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 сентябрендәге 59 номерлы «референдум үткәрүне оештыру турында»гы карары нигезендә, Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2018 елның 18 ноябренә Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

"2019 елда, Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасын җыярга һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

1)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Яңа Кырлай авылы Татарстан урамы-200 м; Яшел урамы-220м;

Яңа Иябаш авылы Татарстан урамы-600м, Елга арты тыкрыгы, Татарстан урамы-Үзәк урамы, Үзәк урамы-Елга арты урамы ;

Чиканас авылы Совет урамы-460м, Октябрь урамы-350м;

Өчиле авылы Интернат-110м, Тукай урамы-350м;

Иске Юрт авылы Клуб урамы-214м;

Югары Бирәзә авылы Ленин урамы -215м;Пәшкәү-110м;

Күкчә Бирәзә авылы Тынычлык урамы - 292м, Аркылы урамы - 385м.

2) Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Яңа Кырлай авылында Ия елгасы яры буенда агач һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару.

3) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (Яңа Иябаш авылы);

-5 данә (Чиканас, Өчиле, Иске Юрт, Югары Бирәзә, Күкчә-Бирәзә авыллары) мотопомпалар сатып алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

Әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 й.,
Татарстан Республикасы, Арча районы, Өчиле авылы, Тукай ур., 73 й.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ